СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.09.2022 г. Заинск № 96

**«Зәй муниципаль районы Зәй шәһәрендә муниципаль хезмәткәр булмаган белгечләргә һәм җирле үзидарә органнарында эшләүчеләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 105 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфа окладларын арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. "Зәй муниципаль районы Зәй шәһәрендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2018 елның 13 апрелендәге карары белән расланган Зәй муниципаль районы Зәй шәһәрендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.2 пунктында«11498 сум» сүзләрен «11958 сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATASTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар 2022 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башлыгы урынбасары Е.В.Недошивинага йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**